# КАРАР

**« 12 » ноябрь 2025 ел № 5**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Хәсәншәех торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында**

"Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2025 елның 12 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены йомгаклау беркетмәсе төзелде:

«2026 елда Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Хәсәншәех авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1 нче группа инвалидлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, түләү күләме 500 сум тәшкил иткән үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш сатып алу; Хәсәншәех авылының Комсомол урамыннан “Киндер күле” чишмәсенә кадәрге җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлын вак таш җәеп тигезләү, Хәсәншәех авылының Комсомол урамыннан “Зөбәйдә” чишмәсенә кадәрге җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы юлын вак таш җәеп тигезләү);
- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәсен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру);
- су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су җыю манараларын, коеларын һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аны чистарту, китерү һәм халыкны су белән тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Хәсәншәех авылында су челтәрләрен ремонтлау);
- коймалар кору, күмү урыннарын төзекләндерү (гербицид сатып алу; зиратны чистарту өчен бензин чапкычы сатып алу; агачларны санитар кисү);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (авылны төзекләндерү җиһазлары өчен запас частьләр сатып алу (бензин чапкычы, бензин пычкысы); авылны төзекләндерү өчен бензин чапкычы, бензин пычкысы сатып алу; агачларны санитар кисү һәм авыл территориясеннән чыгару; Беларус - МТЗ 82.1 тракторының асылмалы фронталь төягеч (КУН, чүмеч) сатып алуны финанслау)?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ””

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучы сайлау хокукына ия затлар исемлегенә 410 граждан, тавыш бирүдә катнашкан 262 кеше кертелде.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашучы 262 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Хәсәншәех торак пунктында халык җыены узды, җыен нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. «2026 елда Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Хәсәншәех авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1 нче группа инвалидлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, түләү күләме 500 сум тәшкил иткән үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш сатып алу; Хәсәншәех авылының Комсомол урамыннан “Киндер күле” чишмәсенә кадәрге җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлын вак таш җәеп тигезләү, Хәсәншәех авылының Комсомол урамыннан “Зөбәйдә” чишмәсенә кадәрге җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы юлын вак таш җәеп тигезләү);

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәсен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру);

- су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су җыю манараларын, коеларын һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аны чистарту, китерү һәм халыкны су белән тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Хәсәншәех авылында су челтәрләрен ремонтлау);

- коймалар кору, күмү урыннарын төзекләндерү (гербицид сатып алу; зиратны чистарту өчен бензин чапкычы сатып алу; агачларны санитар кисү);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (авылны төзекләндерү җиһазлары өчен запас частьләр сатып алу (бензин чапкычы, бензин пычкысы); авылны төзекләндерү өчен бензин чапкычы, бензин пычкысы сатып алу; агачларны санитар кисү һәм авыл территориясеннән чыгару; Беларус - МТЗ 82.1 тракторының асылмалы фронталь төягеч (КУН, чүмеч) сатып алуны финанслау)?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ””

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән 7 көн эчендә, ТР, Арча районы, Хәсәншәех авылы, Татарстан урамы, 42 йорт, Космонавтлар урамы, 20 йорт, Комсомол урамы, 31 йорт адреслары буенча мәгълүмат стендларында, Арча муниципаль районының (http://arsk.tatarstan.ru) рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Апаз авыл җирлеге башлыгы Р.Ф.Котдусов